РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 ноябрь, 2025 Кукмара ш. № 12

Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 28 гыйнварындагы 02 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1 Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 28 гыйнварындагы 02 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 8 ноябрендәге 54 номерлы, 2014 елның 25 июлендәге 36 номерлы, 2016 елның 29 мартындагы 32 номерлы, 2016 елның 26 маендагы 43 номерлы, 2016 елның 9 сентябрендәге 58 номерлы, 2016 елның 18 ноябрендәге 67 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы 78 номерлы, 2017 елның 14 июлендәге 104 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 169 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 182 номерлы, 2019 елныңң 22 мартындагы 209 номерлы, 2020 елның 13 мартындагы 273 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге 291 номерлы; карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.2 пунктындагы 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен – югары белем булу; вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен - югары белем яисә урта һөнәри белем булу.»;

Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.2 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.

Өлкән һәм кече төркемнәрдәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларындагы һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларындагы һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларындагы эш стажы да исәпкә алына.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев